Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы
КАРАРЫ

19 май 2021ел

№ 19

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендәге «Рус Акташы авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы ражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләртурында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Рус Акташы авыл Башкарма комитетына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә» турында 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар,муниципаль вазыйфа яки контракты буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында»Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2021 елның 19 марта 02-08-02/243 номерлы күрсәтмәсе нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендәге «Рус Акташы авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Рус Акташы авыл Башкарма комитетына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә» турында 135 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге №460 номерлы Указы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Татарстан